ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.04.2020 Олы Кайбы ч ав. № 229

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендәге, өченче зат хокукларыннан ирекле булган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына биләүгә һәм (яисә) аннан файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән муниципаль мөлкәт исемлегенә өстәмәләр кертү турында

Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын төзүче оешмаларга «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә мөлкәти ярдәм күрсәтү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендәге муниципаль мөлкәтнең өченче зат хокукларыннан азат булган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына биләүгә һәм (яисә) файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендәге муниципаль мөлкәт исемлеген раслау турында» 2019 елның 04 июлендәге 309 номерлы карары белән расланган кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына биләүгә һәм (яисә) файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән муниципаль мөлкәт исемлеген түбәндәге эчтәлекле 6 пункт белән тулыландырырга:

| п/п | Мөлкәт исеме | Бинаның гомуми мәйданы | Урнашу урыны (адресы) |
|---|---|---|---|
| 6 | | 143,4 | Татарстан Республикасы, Кайбыч |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 16:21:000000:511 кадастр номерлы клуб бинасы (гамәлдә түгел) | | районы, Олы Подберезье авыл җирлеге, Плетени ав., Урман ур., 57 |

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ Рәисе О.Д.Макаровага йөкләргә.

Җитәкче А.Н.Макаров